Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы

**КАРАР №17**

Рус Әшнәге авылы 2017 ел, 7 ноябрь

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеген шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына тапшыру турында 2016 елның 15 декабрендәге Килешүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеген шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорты адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга .

3.Әлеге карарның рәсми рәвештә бастырып чыгарылган (халыкка белдерелгән) көннән үз көченә керүен һәм 2017 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таралуын билгеләргә.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Башлыгы В.Һ.Хаҗиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының
2017 елның 7 ноябрендәге
17 номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**
**“Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеген**
**шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү, раслау**
**һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе турында**
**Нигезләмә**

I.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеген шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен тәгаенли.

1.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеген шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары (алга таба – шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары) җирлекнең җирле әһәмияттәге Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 маддәсе 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән өлкәләргә кагылучы объектлар, территорияләрне төзекләндерү объектлары, җирлек халкының җирле әһәмияттәге бүтән объектлар белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм мондый объектларның җирлек халкы өчен территория ягыннан караганда йөри алырлык мөмкин булган максималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре җыелмасын билгелиләр.

1.3. Шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү түбәндәгеләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендәге халыкның социаль-демографик составын һәм тыгызлыгын;

2) муниципаль берәмлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеш планнарын һәм программаларын;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының һәм кызыксынучы затларның тәкъдимнәрен.

1.4. Шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары үз эченә ала:

1)төп өлешне (муниципаль берәмлек халкының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.2 маддәсенең 4 өлешендә каралган объектлар белән тәэмин ителешенең мөмкин булган минималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм муниципаль берәмлек халкы өчен территория ягыннан караганда йөри алырлык мөмкин булган максималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре);

2) шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларының төп өлешендәге исәп-хисап күрсәткечләрен дәлилләү буенча материаллар;

3) шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларының төп өлешендәге исәп-хисап күрсәткечләрен куллану кагыйдәләре һәм куллану өлкәсе.

1.5.Шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү буенча әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган мөнәсәбәтләргә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә мөнәсәбәтләрне көйләүче Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив-хокукый актлары, шулай ук Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары нормалары кулланыла.

## II. Шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау тәртибе

2.1. Шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү турында карар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә һәм муниципаль хокукый акт рәвешендә рәсмиләштерелә.

2.2.Шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү турындагы карарда тәгаенләнә:

-шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларында чагылдырылырга тиешле исәп-хисап күрсәткечләренең исемлеге;

-шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проектларын әзерләү срокларына күрсәтмәләр;

- кызыксынучы затлар тарафыннан шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләүгә кагылган тәкъдимнәрне тапшыру сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматлар;

-шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү буенча финанслау шартлары һәм эшне оештыруның бүтән мәсьәләләре .

2.3. Шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан мөстәкыйль рәвештә яисә законда каралган товарлар сатып алу, эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы тәртибендә гамәлгә ашырыла.

2.4.Вәкаләтле орган:

-шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проектларын хәзерләү буенча эшләрне оештыруны гамәлгә ашыра;

- шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын әзерләүгә катнашы булган кызыксынучы затларның тәкъдимнәрен җыюны тәэмин итә;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советының шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау яки аларга үзгәрешләр кертү турындагы карар проектын әзерли.

2.5.Вәкаләтле орган шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проектын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Рус Әшнәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары, Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм күрсәтелгән нормативларны кабул итүдә кызыксынулары булган оешмалар (алга таба – кызыксынучы оешмалар), дәүләт күзәтчелек органнары белән килештерүне гамәлгә ашыра.

Шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проектын кызыксынучы органнар белән килештерү срогы шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проекты килештерү өчен аларга кергән көннән исәпләгәндә утыз календарь көнне тәшкил итә.

Кызыксынучы органнардан вәкаләтле органга билгеләнгән срокта шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проектына бәяләмәләр кермәгән очракта әлеге проект килештерелгән булып санала.

2.6.Вәкаләтле орган шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проектын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны һәм муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми рәвештә бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә раслауга кадәр ике айдан да ким булмаган срокта аны бастырып чыгаруны тәэмин итә.

2.7. Әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктында күрсәтелгән срок чыкканнан соң вәкаләтле орган 5 (биш) календарь көн дәвамында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проектын эшләп тәмамлый һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башлыгына тәкъдим итә. Кергән тәкъдимнәр турында гомумиләштерелгән мәгълүмат һәм бу тәкъдимнәр белән килешүне (килешмәүне) дәлилле нигезләүгә күрсәтмә шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларының эшләп төгәлләнгән проектына мәҗбүри кушымта булып тора.

2.8. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башлыгы шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проекты аңа тәкъдим ителгәннән соң 3 (өч) календарь көн эчендә шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары проектын раслау өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советына җибәрү турында карар кабул итә.

2.9. Шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативлары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана.

2.10. Региональ әһәмияттәге объектлар һәм җирле әһәмияттәге объектлар төрләре буенча шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативларын системалаштыруны тәэмин итү максатларында вәкаләтле орган шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслаганнан яки аларга үзгәрешләр кертелгәннән соң ике эш көне эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы бүлегенә аларны раслау турындагы актның күчермәсен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 12 мартында 149 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативларының Реестрын алып бару Тәртибенең 4 пунктына ярашлы рәвештә мәгълүматларны Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше

проектлаштыру нормативлары Реестрына кертү өчен тапшыра. Документлар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы бүлегенә электрон рәвештә һәм кәгазь мәгълүмат йөрткечтә тапшырыла.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы бүлеге (килештерү буенча) вәкаләтле органнан акт күчермәсен һәм әлеге пунктның 1 абзацында күрсәтелгән мәгълүматларны алганнан соң өч эш көне эчендә акт күчермәсен һәм әлеге пунктның 1 абзацында күрсәтелгән мәгълүматларны Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативлары Реестрына кертү өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына тапшыра. Документлар электрон рәвештә һәм кәгазь мәгълүмат йөрткечтә тапшырыла.

2.11.Вәкаләтле орган расланган шәһәр төзелеше проектлаштыру нормативларын күрсәтелгән нормативларны раслаган көннән соң биш көннән артмаган срокта территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмати системасында урнаштыруны тәэмин итә.

## III. Шәһәр төзелеше проектлаштыру җирле нормативларына үзгәрешләр кертү

Шәһәр төзелеше проектлаштыру җирле нормативларына үзгәрешләр кертү шәһәр төзелеше проектлаштыру җирле нормативларын әзерләү һәм раслау өчен әлеге Нигезләмә белән тәгаенләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.